КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 июль г.Казань № 553

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең норматив санын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең норматив санын кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле

Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең норматив санын билгеләү турында» 2023 ел, 1 ноябрь, 1398 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 13 июль, 553 нче
карарына кушымта

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына
Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең
норматив саны

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Хезмәткәрләр саны, берәмлек |
|---|---|---|
| 1. | Әлмәт муниципаль районы | 1 |
| 2. | Югары Ослан муниципаль районы | 1 |
| 3. | Биектау муниципаль районы | 1 |
| 4. | Алабуга муниципаль районы | 1 |
| 5. | Зеленодольск муниципаль районы | 1 |
| 6. | Лаеш муниципаль районы | 1 |
| 7. | Түбән Кама муниципаль районы | 1 |
| 8. | Питрәч муниципаль районы | 1 |
| 9. | Яр Чаллы шәһәре | 4 |
| 10. | Казан шәһәре | 10 |

___